ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ ___202_____

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_16__» ____11_____ 2020_ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25 декабрендәге 479 номерлы, 2020 елның 3 августындагы 151 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт

функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең 2020
елның «16»____11____ _202_
номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Административ регламентның 2 бүлегендәге 2.14 пунктында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү ТР Дәүләт торак инспекциясенең янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән бинасында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, ТР Дәүләт торак инспекциясе биналарыннан, бүлмәләреннән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

ТР Дәүләт торак инспекциясе территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасында һәм бүлмәләрендә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасыннан, бүлмәләреннән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясы.